Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге
Белкино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

14 октябрь, 2022 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлегенең Белкино торак пунктында 2022 елның 14 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 139 (йөз утыз тугыз);
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 79 (җитмеш тугыз);
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 79 (җитмеш тугыз);
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә түбәндәге сорау буенча **гражданнар җыены карары**: «Сез 2023 елда Белкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми кулланылыштагы урыннарны төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Белкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Белкино авыл җирлеге башлыгы А.Н. Меньшов